**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АПАС ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОГЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫНЫҢ**

**КАРАРЫ**

2022 ел, 5 апрель № 20

**Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр тибындагы поселогы башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас авыл җирлеге Башкарма комитетының «муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2020 елның 10 августындагы 95 номерлы карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.4 пунктының икенче баганасындагы беренче абзацында «10 эш көне» сүзләрен «7 (җиде) эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

2) 3.5.1 пунктының җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар запросларга җаваплар килгәннән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча халыкка игълан итәргә (бастырып чыгарырга) һәм авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Ф.Ә. Шәрәфетдинов